ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
САВРУШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

# КАРАР

№ 1 25. 01. 2021ел

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлегендәҗирләү буенча хезмәтләрнең
гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган
хезмәтләрнең хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эшетурында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Савруш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1.2021 елның 1 февраленнән Аксубай муниципаль районының Савруш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрең гарантияле исемлеге нигезендә 6189,10 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын, 1 һәм 2 нче кушымталарга туры китереп, билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Савруш авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында» 2020 елның 30 гыйнварындагы 1 номерлы карары 2021елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (http://aksubayevo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырыпчыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарның үтәлешен контроль дәтотам.

Савруш авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: А.Г.Кузьмин

Аксубаймуниципаль районы
Савруш авыл җирлеге
Башкармакомитетының
2021 елның 25 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
1 нчекушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Савруш авыл җирлегендә җирләү буенча
Хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәткүрсәтүисеме | Хезмәткүрсәтүхакы (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләүеченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | - |
| 2. Җирләүеченкирәклетабутһәм башка предметларныбирүһәмкитерү | 2284,80 |
| 3. Мәрхүмнеңмәетен (җәсәдләрен) зираткаалып бару | 920,00 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәмкүмү ) | 2984,30 |
| Барлыгы | 6189,10 |

Аксубай муниципаль районы
Савруш авыл җирлеге
Башкармак омитетының
2021 елның 25 гыйнварындагы
1 номерлы карарына
2 нчекушымта

2021 елның 1 февраленнән
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районының
Савруш авыл җирлегендә җирләү буенча
Хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| Хезмәткүрсәтүисеме | Хезмәткүрсәтүхакы (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләүеченкирәкледокументларнырәсмиләштерү | - |
| 2. Мәетнекафенгәтерү | 394,00 |
| 3. Җирләүеченкирәклетабутһәм башка предметларныбирүһәмкитерү | 1890,8 |
| 4. Мәрхүмнеңмәетен (җәсәдләрен) зираткаалып бару | 920,00 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәмкүмү ) | 2984,3 |
| Барлыгы | 6189,1 |